| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ<br>ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ<br>И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ<br>ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ<br>ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

21.07.2017 № 438

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазифаларына урнашуга дәгъвалаучы гражданнарның һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең “Интернет” мәгълүмат һәм телекоммуникация челтәрендә һәркем күрә алырлык, шулай да аларны таныйрлык мәгълүматы кертелгән сайт адреслары һәм (яисә) сайт сәхифәләре турында мәгълүматларны алу, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында

“Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2004 ел 27 июль № 79-ФЗ Федераль законының 20.2 мәкаләсенә, “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2003 ел 16 гыйнвар № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 17.2 мәкаләсенә карата б о е р а м:

1. Кушылган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазифаларына урнашуга дәгъвалаучы гражданнарның һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең “Интернет” мәгълүмат һәм телекоммуникация челтәрендә һәркем күрә алырлык, шулай да аларны таныйрлык мәгълүматы кертелгән сайт адреслары һәм (яисә) сайт сәхифәләре турында мәгълүматларны алу, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкны министр урынбасарларына, министрлыкның структура бүлекләренең җитәкчеләренә һәм дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Әлеге боерыкны башкару контролен министр урынбасары О.А. Степущенкога йөкләргә.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

21 июль 2017 ел № 438
Татарстан Республикасы ГТХМ
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазифаларына урнашуга дәгъвалаучы гражданнарның һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең "Интернет" мәгълүмат һәм телекоммуникация челтәрендә һәркем күрә алырлык, шулай да аларны таныырлык мәгълүматы кертелгән сайт адреслары һәм (яисә) сайт сәхифәләре турында мәгълүматларны алу, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе

## I. Гомуми кагыйдәләр

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХМ) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазифаларына урнашуга дәгъвалаучы гражданнарның һәм Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең "Интернет" мәгълүмат һәм телекоммуникация челтәрендә һәркем күрә алырлык, шулай да аларны танырлык мәгълүматы кертелгән сайт адреслары һәм (яисә) сайт сәхифәләре турында мәгълүматларны алу, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе (алга таба – Тәртип) билгеләп куя:

Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазифаларына урнашуга дәгъвалаучы гражданнары (алга таба – гражданин) һәм Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХМ гражданлык хезмәткәре) "Интернет" мәгълүмат һәм телекоммуникация челтәрендә һәркем күрә алырлык, шулай да аларны танырлык мәгълүматы кертелгән сайт адреслары һәм (яисә) сайт сәхифәләре турында мәгълүматларны (алга таба – Сайтлар турында мәгълүматлар, "Интернет" челтәре) тапшыру кагыйдәләрен;

Сайтлар турында мәгълүматларны алу һәм эшкәртү тәртибен;

Сайтлар турында мәгълүматларның ышанычлыгын һәм тулылыгын тикшерү тәртибен;

2. "Мәгълүмат, информацион технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында" 2006 ел 27 июль № 149-ФЗ Федераль законының 7 мәкаләсе 1 бүлегенә карата һәркем күрә алырлык мәгълүмат һәркемгә белерлек мәгълүматлар һәм рөхсәте чикләнмәгән мәгълүмат дип аңлана. Шул ук вакытта мәгълүматка рөхсәтне чикләү булмау чикләнмәгән затлар даирәсе киртәсез рәвештә һәм үзе теләгәнчә кертелгән мәгълүматны гражданлык хезмәткәре яисә гражданинның ризалыгысыз куллануны билгели.

3. Бу мәгълүматларның бөтенесе яисә аларның берсе генә гражданлык хезмәткәренең яисә гражданинның шәхесен таныта ала торган мәгълүмат булырга мөмкин: фамилия һәм исем, фотография, хезмәт урыны.

## II. Сайтлар турында мәгълүматны алу һәм эшкәртү тәртибе

4. Сайтлар турында мәгълүматларны тапшыралар:

гражданин – Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә (алга таба – гражданлык хезмәте) кергән вакытта гражданлык хезмәтенә керү елы алдыннан өч календарь елы өчен;

Татарстан Республикасы ГТХМ гражданлык хезмәткәре – отчет елыннан барган елның 1 нче апреленнән соңга калмыйча ел саен үткән календарь елы өчен.

5. Гражданнар һәм гражданлык хезмәткәрләре сайтлар турында мәгълүматларны Русия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләп куелган форма (алга таба – Форма) буенча тапшырыла.

6. Һәркем күрә алырлык мәгълүмат, әгәр ул гражданлык хезмәткәренең вазифа бурычларын башкару чикләрендә кертелгән булса, Формада күрсәтелергә тиеш түгел.

7. Гражданлык хезмәткәре яисә гражданин тутырылган Форманы Татарстан Республикасы ГТХМ ның кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән Сайтлар турында мәгълүматларны эшкәртүне башкарырга җаваплы булып билгеләнгән хезмәткәренә (алга таба – җаваплы шәхес) тапшырыла.

8. Форманы алу көнендә җаваплы шәхес Форманың бөтенләй тутырылганлыгын, “Интернет” челтәрен кулланып Формада язылган мәгълүматларның ышанычлыгын тикшерә, үзенең имзасын куя, әлеге Тәртипнең Кушымтасындагы формасы буенча журналга мәгълүматларны кертә.

9. Тутырылмаган урыннары булган Форма алынмаска тиеш.

10. Гражданин тапшырган Формада ышанычсыз мәгълүматлар табылган очракта Татарстан Республикасы ГТХМ ның кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге гражданинны гражданлык хезмәтенең вазифасына урнаштыруда кире кагу турында аны кичектермичә белдерә.

11. Җаваплы шәхес Сайтлар турында мәгълүматларны “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәтнең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм информацион системасы” Татарстан Республикасы дәүләт информацион системасында гражданлык хезмәткәрләренең шәхси карточкаларына кертә.

12. Гражданлык хезмәткәрләре һәм гражданнар тапшырган Формалар кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегендә биш ел буе саклана, аннан соң Татарстан Республикасы ГТХМ да Шәхси мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләре белән билгеләп куелган тәртиптә бетерелергә тиеш.

## III. Сайтлар турында мәгълүматларның ышанычлыгын һәм тулылыгын тикшерү тәртибе

13. Татарстан Республикасы ГТХМ гражданлык хезмәткәрләре тапшырган Сайтлар турында мәгълүматларның ышанычлыгын һәм тулылыгын тикшерү министр (министр вазифаларын башкаручы шәхесе) боерыгы буенча башкарыла.

14. Түбәндәгеләр язу төрендә тапшырган җитәрлек мәгълүмат тикшерү өчен нигез булып тора:

хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазифалы шәхесләре;

сәяси партияләрнең даими эшли торган җитәкче органнары һәм сәяси партияләр булмаган законга туры китереп теркәлгән башка гомумрусия, регионара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләр;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы;

гомумрусия һәм республиканың массакүләм мәгълүмат чаралары.

15. Җаваплы шәхес гражданлык хезмәткәрен аның тарафына тикшерү башланганы турында язу формасында тикшерүне үткәрү турында боерык чыккан көненнән бирле ике эш көне эчендә белдерә.

16. Гражданлык хезмәткәре тапшырган Сайтлар турында мәгълүматларның ышанычлыгын һәм тулылыгын тикшерү ул “Интернет” челтәренә кертқән һәркем күрә алырлык мәгълүматны эзләү һәм билгеләнгән мәгълүматның электрон күчермәләрен (скриншотларны) кору ярдәме белән җаваплы шәхес белән башкарыла.

17. Гражданлык хезмәткәре тикшерү вакытында һәм аның нәтиҗәләре буенча язу формасында аңлатмалар бирергә, өстәмә материаллар бирергә хаклы.

18. Әлеге Тәртипнең 17 пунктында билгеләнгән аңлатмалар тикшерү материалларына беркетелә.

19. Тикшерү материаллары һәм тикшерү вакытында җыелган мәгълүмат министрга тикшерүне үткәрү турында боерык чыгарылган көннән бирле 10 эш көненнән соңга калмыйча тапшырыла.

20. Тикшерү нәтиҗәләре буенча министр 5 көнлек вакытта карар кабул итә:

юридик җаваплылык чараларын гражданлык хезмәткәренә кабул итәр өчен сәбәпләр булмау турында;

юридик җаваплылык чараларын гражданлык хезмәткәренә кабул итү турында;

хокук бозу, җинаять, экстремизм эшенә катнашы булганда тикшерү материалларын компетенцияләренә карата дәүләт органнарына җибәрү турында;

21. Җаваплы шәхес министрның кабул ителгән карары турында тикшерелгән гражданлык хезмәткәрен ике эш көне эчендә язу формасында белдерә.

22. Министрның язу рөхсәтеннән Сайтлар турында мәгълүмат берьюлы тикшерелгән гражданлык хезмәткәрен белдерүе белән тикшерүне үткәрер өчен нигез булган мәгълүматны тапшырган хокук саклау органнарына, сәяси партияләрнең даими эшли торган җитәкче органнарына һәм сәяси партияләр булмаган законга туры китереп теркәлгән башка гомумрусия, регионара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләргә, Татарстан Республиксы Иҗтимагый палатасына, гомумрусия һәм республиканың массакүләм мәгълүмат чараларына, шәхси мәгълүматлар һәм дәүләт сере турында Русия Федерациясе законнарын үтәп, тапшырылырга мөмкин.

23. Тикшерү материаллары Татарстан Республикасы ГТХМ кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегендә тикшерү тәмамланган көненнән бирле өч ел буе саклана, шуннан соң архивга тапшырыла.

## IV. Сайтлар турында мәгълүматларны тапшырмау өчен җаваплылык

24. Сайтлар турында мәгълүматларны тапшырмаган очракта гражданин гражданлык хезмәтенә кабул ителә алмый, ә гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәтендә була алмый.

25. Татарстан Республикасы ГТХМ гражданлык хезмәткәре Сайтлар турында мәгълүматларны тапшырмау хокук бозу булып тора һәм гражданлык хезмәтеннән чыгаруга китерә.

21.07.2017 № 438
Татарстан Республикасы ГТХМ
боерыгы белән расланган
Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазифаларына урнашуга дәгъвалаучы гражданнарның һәм Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең “Интернет” мәгълүмат һәм телекоммуникация челтәрендә һәркем күрә алырлык, шулай да аларны танырлык мәгълүматы кертелгән сайт адреслары һәм (яисә) сайт сәхифәләре турында мәгълүматларны алу, эшкәртү һәм тикшерү тәртибенә
кушымта

## Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазифаларына урнашуга дәгъвалаучы гражданнарның һәм Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең “Интернет” мәгълүмат һәм телекоммуникация челтәрендә һәркем күрә алырлык, шулай да аларны танырлык мәгълүматы кертелгән сайт адреслары һәм (яисә) сайт сәхифәләре турында тапшырылган мәгълүматларны исәпләү журналы

| № т/б | Форманы тапшыру/алу датасы | Форманы тапшырганның исеме, фамилиясе, атасының исеме | Форманы тапшырганның вазифасы (гражданин дәгъвалый торган вазифа) | Форманы тапшырганның имзасы (яисә форма почта аша килсә, килгән хатның номеры) | Форманы кабул иткән шәхеснең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Форманы кабул иткән шәхеснең имзасы | Тикшерү турында мәгълүмат (боерык реквизитлары, тикшерү нәтиҗәләре) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |